КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 24 гыйнвар г.Казань № 30

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 елга Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Юлламасын тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәте гамәлләренең комплекслы планы турында» 2023 ел, 16 октябрь, 1309 нчы карары белән расланган 2024 елга Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Юлламасын тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәте гамәлләренең комплекслы планына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 елга Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Юлламасын тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәте гамәлләренең комплекслы планы турында» 2023 ел, 16 октябрь, 1309 нчы карары белән расланган 2024 елга Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Юлламасын тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәте гамәлләренең комплекслы планына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктка түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | «41. Фәнне популярлаштыру, алга этәрү системасын һәм республика проектларын һәм технологияләрен булдыру, Татарстан Республикасының югары белем бирүнең төп белем бирү оешмаларының, фәнни мәктәпләрнең һәм үсеш институтларының танылуын һәм академик репутациясен арттыру | ел дәвамында | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе |
| | | 42. Татарстан Республикасы югары белем бирү оешмаларының, академик оешмаларының һәм предприятиеләренең фәнни-технологик казанышларын популярлаштыру максатларында «Балкыш» даими телепрограммасын булдыру | IV квартал | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе, Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы |
| | | 43. «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе җитәкчелегендә робототехника, ясалма интеллект һәм пилотсыз транспорт системалары өлкәсендә Татарстан Республикасы компетенцияләр үзәкләрен төзү буенча эш төркеме формалаштыру | ел дәвамында | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы, бүтән республика башкарма хакимият органнары |
| | | 44. Фәнни-мәгариф оешмаларының республиканың социаль-икътисадый үсешенә керткән өлеше дәрәҗәсен бәяләү буенча фәнни-тикшеренү проектын гамәлгә ашыру («югары белем бирү оешмаларының төбәк үсешенә йогынтысы рейтингы»). | ел дәвамында | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы»; |

4 пунктка түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | «111. «Татарстан Республикасы өчен илле иң яхшы инновацион идея» республика конкурсын оештыру һәм уздыру | ел дәвамында | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Татарстан Республикасы инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешмасы |
| | | 112. Татарстан Республикасында интеллектуаль милек базарын үстерүгә юнәлдерелгән чараларны алга таба гамәлгә ашыру буенча комплекслы тәкъдимнәр әзерләү | ел дәвамында | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, башка республика башкарма хакимият органнары»; |

6 пунктка түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | «221. IT-грамоталылык өлкәсендә белгечләр әзерләү һәм квалификациясен күтәрү өлкәсендә өстәмә белем бирү программаларын эшләү | ел дәвамында | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |
| | | 222. Һөнәри белем программалары буенча белем алучылар өчен IT-олимпиадалар оештыру һәм уздыру | ел дәвамында | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |
| | | 223. Уйлап табучылык эшчәнлегенә ярдәм итүнең республика үзәкләрен ачу | ел дәвамында | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы; |

14 пунктка түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | «411. Тәҗрибә, алдынгы карарлар алмашу, үз-үзеңне оештыру һәм үзлегеннән белем алу өчен Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе тарафыннан Татарстан Республикасы индустриаль өлкәсендә гомуми платформа, бердәм чимал һәм компонент базасы һәм Бердәм Цифрлы университет белән берләштерелгән унификацияләнгән стандартлар белән бердәм бизнес-киңлек эшләү | ел дәвамында | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе |
| | | 412. Фәнни-тикшеренү продукциясен башкаручыларның һәм кулланучыларның бердәм челтәренә интеграцияләүче Smart Market-Space төбәк цифрлы платформасын эшләү һәм үстерү | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы |
| | | 413. Фәнни үзәкләрнең һәм оешмаларның югары белем бирү мәгариф оешмалары, фәнни оешмалар бүлекчәләре һәм «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесенең структуралары белән озак сроклы партнерлык кооперациясе схемасын эшкәртү | ел дәвамында | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, бүтән республика башкарма хакимият органнары; |

38 пунктка түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | «951. Белем бирү мохитенең яңа концепциясен булдыру һәм аңа күчү | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Респуб- |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | («Татарстан Республикасының фәнни-технологик үсеше» программасы кысаларында мәктәпләрдә мәгълүмат-компьютер технологияләре ярдәмендә физика, математика, биология һәм химияне өйрәнү) | | ликасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары (килешү буенча) «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе; |

40 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «40. | Беренчел звено сәламәтлек саклау системасының мөһим өлеше булып тора. Монда элеккечә кадрлар җитмәү проблемасы саклана. Бу булган персоналның эше артык күп булуына китерә, медицина ярдәменең сыйфатына турыдан-туры тискәре йогынты ясый. Бу мәсьәлә Зеленодольск, Түбән Кама һәм Бөгелмә районнарында аеруча кискен тора. Республика Сәламәтлек саклау министрлыгына, район башлыклары белән берлектә, мәсьәләне хәл итү буенча тәкъдимнәр кертергә тәкъдим итәм | 107. Сәламәтлек саклау системасында кадрлар җитмәүне бетерү чараларын гамәлгә ашыру:<br>максатчан уку турындагы шартнамә буенча белем алган чыгарылыш ординаторларны медицина оешмалары буенча бүлү;<br>үзәк район хастаханәләренә бүленгән яшь белгечләргә хезмәт урыннан торак бирүне оештыру;<br>медицина хезмәткәрләренә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләре, грантлар, өстәмә акча бирү программаларын гамәлгә ашыру | ел дәвамында | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары (килешү буенча)»; |

46 пунктка түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | «1331. «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесенә һәм аның төп структур бүлекчәләренә аспирантурага МХО катнашучыларын һәм аларның гаилә әгъзаларын кабул итү һәм укыту буенча ташламалар бирү | ел дәвамында | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе; |

48 пунктка түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | «1501. Патриотик юнәлештәге ачык лекцияләр циклын үткәрү | ел дәвамында | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе; |

49 пунктка түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | «1551. Яшь галимнәр арасында «Татарстан Республикасының иң яхшы яшь галиме» республика конкурсын оештыру һәм уздыру | ел дәвамында | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы |
| | | 1552. «Татарстан Республикасы постдок» кадрлары җәлеп итү программасын башлап җибәрү | ел дәвамында | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |
| | | 1553. «Татарстан Республикасы чакырылган галиме» кадрлары җәлеп итү программасын башлап җибәрү | ел дәвамында | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы; |

52 пунктка түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | «1851. XI Болгар халыкара археология мәктәбе эшен оештыру | ел дәвамында | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы»; |

56 пунктка түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | «1991. БРИКС илләренең Академия советын формалаштыру | IV квартал | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе, Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгы, Татарстан Республикасы Туризм буенча дәүләт комитеты, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, башка республика башкарма хакимият органнары |
| | | 1992. БРИКС илләре фәнни төркемнәренең уртак фәнни тикшеренүләре, проектлары конкурс-ларына ярдәм итүне башлап җибәрү | IV квартал | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе. |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин